# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлеге Советы карары

102а№ 2014 елның 04 августы

Иске Матак авыл җирлеге Советының 2012 елның 2 апрелендәге «ТР Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 51 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2014 елның 7 мартындагы «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләре законлы көченә керүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Матак авыл җирлеге Советының 2012 елның 2 апрелендәге «ТР Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 51 номерлы карарына (алга таба - Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кагыйдәнең 8.10.2., 8.10.5, 8.10.6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

Кагыйдәнең 8.10.7 пункты «Авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын тоту тәртибе авыл җирлеге вәкиллекле органы карары белән билгеләнә» кагыйдәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Йорт хайваннарын тоту тәртибе Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә».

2.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлеге мәгълүмат стендында урнаштырырга.

Әлки муниципаль районы Иске
Матак авыл җирлеге башлыгы
Совет Рәисе Г.В.Нагорнов